ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 516-94/тэ-2020

«Интерграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә 2021-2025 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 516-94/тэ-2020
карарына 1 нче кушымта

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан
күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2021-2025 елларга
календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык китерү матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта, – кулланучылар өчен | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 560,64 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 572,94 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 572,94 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 604,42 | - |
| | | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 592,33 | - |
| | | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 604,84 | - |
| | | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 604,84 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 614,71 | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 614,71 | - |
| | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 629,46 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 516-94/тэ-2020
карарына 2 нче кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2021-2025 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җылылык челтәренең матди характеристикасына технологик югалтулар күләменең мөнәсәбәте | Технологик югалтулар |
| | | | мең сум | % | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| Казан шәһәре | | | | | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ | 2021 | 36 830,41 | 1 | 0,61 | 9 489,98 |
| | | 2022 | X | 1 | 0,61 | 9 489,98 |
| | | 2023 | X | 1 | 0,61 | 9 489,98 |
| | | 2024 | X | 1 | 0,61 | 9 489,98 |
| | | 2025 | X | 1 | 0,61 | 9 489,98 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге